ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.11.2022 Казан ш. № 590-164/кс-2022

«Пласт басымын саклап тоту өчен технологик сыекча әзерләү идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчәргә яраклы суга һәм техник суга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 02.12.2020 №332-142/кс-2020 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2023 елга төзәтмә кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 18 ноябрендәге 39-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә, 2023 елга җайга салынулы оешманың эчә торган суга, техник суга озак сроклы тарифларына һәм кирәкле тулай табышына төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2021-2023 елларга «Пласт басымын саклап тоту өчен технологик сыекча әзерләү идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчәргә яраклы суга һәм техник суга тарифлар билгеләү турында» 02.12.2020 №332-142/кс-2020 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 08.12.2021

№460-127/кс-2021 карары керткән үзгәреш белән) 1 нче кушымтага үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар белән төзәтелгән 2023 елга тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Пласт басымын саклап тоту өчен технологик сыекча әзерләү идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчәргә яраклы суга һәм техник суга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 02.12.2020 №332-142/кс-2020 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 елга төзәтмә кертү хакында» 08.12.2021 №460-127/кс-2021 карарын көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.11.2022 № 589-163/кс-2022
карарына 1 нче кушымта

## 2021-2023 елларга салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Пласт басымын саклап тоту өчен технологик сыекча әзерләү идарәсе» ҖЧҖ өчен эчәргә яраклы суга һәм техник суга тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Техник су тарифы (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| 1 | «Пласт басымын саклап тоту өчен технологик сыекча әзерләү идарәсе» ҖЧҖ (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча күрсәтелгән), технологик яктан үзара бәйләнмәгән берничә үзәкләштерелгән система булуына карап, тарифларны дифференциацияләү: | | | |
| 1.1 | өслектәге су чыганакларыннан – Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге кулланучылары | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 7,77 | |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 8,04 | |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 8,04 | |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 8,26 | |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 8,56 | |
| 1.2 | өске су чыганакларыннан – «Зәй шәһәре» муниципаль берәмлеге кулланучылары | 01.01.2021 башлап | 10,73 | |

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Техник су тарифы (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | | 30.06.2021 кадәр | | |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 10,73 | |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 10,73 | |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 11,23 | |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 11,63 | |
| 1.3 | өске су чыганакларыннан – «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге кулланучылары | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 16,82 | |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 16,82 | |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 16,82 | |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 17,39 | |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 18,25 | |
| 1.4 | өске су чыганакларыннан – «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге кулланучылары | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 17,57 | |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 17,57 | |

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Техник су тарифы (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 17,57 | |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 18,16 | |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 19,07 | |
| 1.5 | өске су чыганакларыннан – «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге кулланучылары | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 19,59 | |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 19,59 | |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 19,59 | |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 20,18 | |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 21,26 | |
| 1.6 | өске су чыганакларыннан – «Лениногорск шәһәре» муниципаль берәмлеге кулланучылары | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 20,47 | |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 20,47 | |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 20,47 | |
| | | 01.07.2022 | 21,07 | |

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Техник су тарифы (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | | башлап 31.12.2022 кадәр | | |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 22,22 | |
| 1.7 | өслектәге су чыганакларыннан – «Чаллы шәһәре», «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлекләре, Тукай муниципаль районының «Нефтебаза бистәсе» кулланучылары. | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | | 8,18 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | | 8,18 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | | 8,18 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | | 8,40 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | | 8,62 |
| 1.8 | өске су чыганакларыннан – «Азнакай шәһәре», «Әлмәт шәһәре», «Баулы шәһәре», «Бөгелмә шәһәре», «Зәй шәһәре», «Нурлат шәһәре», «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлекләре кулланучылары (су әзерләүгә кадәрге су) | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | | 31,26 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | | 31,26 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | | 31,26 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | | 33,08 |
| | | 01.01.2023 башлап | | 33,46 |

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Техник су тарифы (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | | 31.12.2023 кадәр | | |
| 1.9 | өске су чыганакларыннан – «Азнакай шәһәре», «Әлмәт шәһәре», «Баулы шәһәре», «Бөгелмә шәһәре», «Алабуга шәһәре», «Зәй шәһәре», «Нурлат шәһәре», «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлекләре кулланучылары (пласт басымын саклау системасы өчен) | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | | 31,44 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | | 31,44 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | | 31,44 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | | 33,29 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | | 33,66 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге